КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 2 сентябрь г.Казань № 950

Федераль бюджеттан финанслаша торган авыл туризмын үстерү проектларын тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан «Агротуризм» грантларын бирү тәртибе
Татарстан Республикасы бюджетыннан «Агротуризм» грантларын бирү тәртибе

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Федераль бюджеттан финанслаша торган авыл туризмын үстерү проектларын тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан «Агротуризм» грантларын бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 2.2 пунктындагы өченче абзацыннан һәм 5.4 пунктыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин